КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1217

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 206 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 874 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1099 нчы; 2019 ел, 9 сентябрь, 805 нче; 2020 ел, 3 декабрь, 1091 нче; 2021 ел, 19 июль, 593 нче; 2022 ел, 3 июнь, 519 нчы; 2022 ел, 3 октябрь, 1059 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең 1.2 бүлекчәсендә:

икенче абзацта «2 – 6 нчы таблицаларда» сүзләрен «2 – 5 нче таблицаларда» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче таблицаның 2 пунктындагы 6 графасында «шәһәр җирлекләрендә һәм шәһәр округларында – 10; авыл җирлекләрендә – 20» сүзләрен «шәһәр торак пунктларында – 10; авыл торак пунктларында – 20» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче таблицаның искәрмәләрендә:

1 пунктта «Җирлекләр һәм шәһәр округлары» сүзләрен «Торак пунктлар чикләрендәге» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Искәрмәләрнең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне үтәүгә юнәлдерелгән чаралар җирлекләрнең һәм шәһәр округларының генераль планнарын нигезләү материалларына, шулай ук торак пунктлар чикләрендәге территорияләрне планлаштыру проектларына аңлатма язулары керергә тиеш.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак пунктлар территорияләрендә янгын сүндерү депосы биналарын урнаштыру буенча янгын куркынычсызлыгының гомуми таләпләре «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законның 17 бүлегендә билгеләнгән.»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Торак пунктлар территорияләрендә янгын сүндерү депосы биналарын урнаштыру шәһәр торак пунктларында чакыру урынына беренче бүлекчә килү вакыты – 10 минуттан, ә авыл торак пунктларында 20 минуттан артмау шартыннан чыгып билгеләнә.»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Торак пунктлар территорияләрендә янгын сүндерү депосы биналарын урнаштыру урыннарын билгеләү тәртибе һәм методикасы янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларда билгеләнә.»;

сигезенче абзацта «җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрендә янгыннан саклау бүлекчәләре дислокациясе урыннарын» сүзләрен «торак пунктлар территорияләрендә янгын депосы биналарын урнаштыру урыннарын» сүзләренә алмаштырырга;

егерме алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шулай итеп, торак пунктлар территорияләрендә янгын сүндерү деполары биналарын урнаштыру буенча янгын куркынычсызлыгы таләпләре тулы күләмдә башкарылсын өчен, генераль планда түбәндәге таләпләр исәпкә алынырга тиеш:»;

утызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Янгын куркынычсызлыгы таләпләре җирлекләрнең һәм шәһәр округларының генераль планнарында исәпкә алынырга һәм торак пунктлар чикләрендәге территориянең планировкасы документларында чагылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин